| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
09 февраль 2024 ел

КАРАР
№2

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында күмү һәм күмү эше турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 20234 елның 23 гыйнвары №46 «2024 елда түләүләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карары нигезендә, Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.2024 елның 1 февраленнән җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2024 елның 1 февраленнән Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Норлат авыл җирлеге башлыгы И.М.Саттаров

Зеленодольск муниципаль районы
Норлат авыл җирлеге башкарма
комитеты 2024 елнын 09 феврале 2 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү гарантияле исемлеге буенча 2024елнын 1 февраленнән башлап хезмәт күрсәтү бәясе.

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 561,35 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1 299,37 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2 509,48 |
| Барлыгы | 8 370,20 |

Зеленодольск муниципаль районы
Норлат авыл җирлеге башкарма
комитеты 2023 елнын 09 феврале 2 нче
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү гарантияле исемлеге буенча 2024елнын 1 февраленнән башлап хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гәүдәне төрү | 805,88 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 755,48 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1 299,37 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү ) | 2 509,47 |
| Барлыгы | 8 370,20 |